СОВЕТ БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БУРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

20.09.2018 с. Татарское Бурнашево № 51-227

Җирле референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст. 1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Бурнаш авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Бурнаш авыл җирлеге территориясендә түбәндәге мәсьәләләр буенча җирле референдум уздыруның уртак инициативасын чыгарырга:

«2019 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия авыл җирлегенең һәр кешесеннән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча алынган акчаларны күчерү белән сез килешәсезме?:

- Татар Борнашы авылында Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәйкәл төзү;

Юмарт авылы ихтыяҗлары өчен вак таш сатып алу;

- Каинка авылында Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәйкәл төзү;.

«ӘЙЕ» «ЮК»

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге башлыгы С. В. Бурукин